Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел № 97

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Уставы нигезендә

Яңа Кәшер авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләүгә ышанычсыз дип тануны 2024 елның 1 январена аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 январена кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 һәм (яисә) 70 статьяларында билгеләнгән сроклар узгач 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырырга, Әлмәт районы, Яңа Кәшер авылы, Тавабилов урамы,153 йорт, Бикасаз авылы, Мәктәп урамы,1А йорт йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Кәшер авыл
җирлеге башлыгы Л.М. Гиниятуллина